Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Бута авыл җирлеге башкарма комитеты
КАРАРЫ

25 июль 2022ел № 9

Әлмәт муниципаль районы Бута авылы башкарма комитетының 2022 елның 6 апрелендәге 5 номерлы «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү сәбәпле, хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча

Бута авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Әлмәт муниципаль районы Бута авылы башкарма комитетының 2022 елның 6 апрелендәге 5 номерлы «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. карарга 1 нче кушымтада:

2.5. бүлеге 2.5.1 пунктындагы 5,6 пунктчаларын төшереп калдырырга;

1.2. 2.6. бүлеге 2.6.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 4 пунктчаны өстәргә:

«4) индивидуаль торак йортка хокук билгели торган документлар (әгәрмилек хокукы Бердәм дәүләт күчем сез мөлкәт реестрында теркәл мәгән булса)".

2. Әлеге карарны Бута ав., Сельская ур., 28А йорт, территориясендә урнашкан махсус стендларда игълан итәргә, шулай ук «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылганнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Бута авылы
башкарма комитеты җитәкчесе Д.Е. Абрамов